| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 27.11.2020 г. Казань № 289-110/кс-2020

«Минзәлә районы коммуналь челтәрләре» акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм су агызуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 № 10-172/кс карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2021 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, эчә торган суга, су агызуга 2021-2023 елларга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай кеременә төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Минзәлә районы коммуналь челтәрләре» акционерлык җәмгыяте өчен 2019-2023 елларга эчә торган суга һәм ташландык суларны агызуга тарифлар билгеләү турында» 14.12.2018 № 10-172/кс карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 № 10-72/кс карары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2018 № 10-172/кс
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
27.11.2020 № 289-110/кс-2020
карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Минзәлә районы коммуналь челтәрләре» акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм су агызуга 2019-2023 елларга кадендарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | Минзәлә муниципаль районы | | | |
| 1 | «Минзәлә районы коммуналь челтәрләре» ачык акционерлык җәмгыяте | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 35,42 | 39,04 |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 36,48 | 40,26 |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 36,48 | 40,26 |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 36,65 | 41,29 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 36,65 | 40,99 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 38,14 | 40,99 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 38,14 | 40,99 |
| | | 01.07.2022 башлап | 39,56 | 42,66 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 31.12.2022 кадәр | | |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 39,56 | 42,66 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 40,27 | 44,33 |
| 1.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 29,52 | 32,53 |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 30,40 | 33,55 |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 30,40 | 33,55 |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 30,54 | 34,41 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 30,54 | 34,16 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 31,78 | 34,16 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 31,78 | 34,16 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 32,97 | 35,55 |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 32,97 | 35,55 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 33,56 | 36,94 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2018 № 10-172/кс
карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
27.11.2020 № 289-110/кс-2020
карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Минзәлә районы коммуналь челтәрләре» акционерлык җәмгыяте өчен 2019-2023 елларга эчә торган суга һәм су агызуга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары

| Т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Минзәлә районы коммуналь челтәрләре» ачык акционерлык җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Эчә торган су | 2019 | 9 017,75 | X | - | 2,4 | 1,644 |
| | | 2020 | X | 1 | - | 2,4 | 1,644 |
| | | 2021 | X | 1 | - | 2,4 | 1,644 |
| | | 2022 | X | 1 | - | 2,4 | 1,644 |
| | | 2023 | X | 1 | - | 2,4 | 1,644 |
| 1.2 | Су агызу | 2019 | 8 026,70 | X | - | - | 1,51 |
| | | 2020 | X | 1 | - | - | 1,51 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 | X | 1 | - | - | 1,51 |
| | | 2022 | X | 1 | - | - | 1,51 |
| | | 2023 | X | 1 | - | - | 1,51 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге